**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «О Республиканском конкурсе «Лучший государственный гражданский служащий Республики Татарстан» и Указ Президента Республики Татарстан «Об Электронной доске почета государственных гражданских служащих Республики Татарстан»**

1. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 16 мая 2014 года № УП-479 «О Республиканском конкурсе «Лучший государственный гражданский служащий Республики Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 27 июня 2015 года № УП-604, от 21 августа 2017 года № УП-719, от 27 февраля 2021 года № УП-188, от 3 сентября 2022 года № УП-618 и Указом Раиса Республики Татарстан от 25 августа 2023 года № 590) следующие изменения:

а) в Положении о Республиканском конкурсе «Лучший государственный гражданский служащий Республики Татарстан»:

пункт 4 изложить в следующей редакции:

«4. Конкурс проводится не реже одного раза в два года.»;

пункт 7 изложить в следующей редакции:

«7. По итогам конкурса:

в каждой конкурсной группе по каждой номинации определяются победители (далее – лауреаты конкурса), при этом общее количество лауреатов конкурса не может превышать 12;

в каждой номинации дополнительно определяются наиболее отличившиеся участники конкурса (далее – призеры конкурса), при этом общее количество призеров конкурса не может превышать 6.»;

в пункте 8 слова «ежегодно не позднее 15 июля» исключить;

в пункте 22 слова «о награждении лауреатов конкурса» заменить словами «о награждении лауреатов конкурса и поощрении призеров конкурса»;

в пункте 23 слова «в размере 50 тысяч рублей» заменить словами «в размере 100 тысяч рублей»;

дополнить пунктами $23^1$ и $23^2$ следующего содержания:

«$23^1$. Призеры конкурса поощряются денежным призом в размере 50 тысяч рублей.

$23^2$. Лауреаты конкурса и призеры конкурса могут быть направлены на обучение по программам повышения квалификации либо профессиональной переподготовки на основании рекомендации Конкурсной комиссии.»;

б) в Положении о Конкурсной комиссии по организации и проведению Республиканского конкурса «Лучший государственный гражданский служащий Республики Татарстан»:

в пункте 4 слова «Татарстанской республиканской организации общественной общероссийской организации «Профессиональный союз работников государственных учреждений и общественного обслуживания Российской Федерации» заменить словами «Татарстанской республиканской организации Общероссийского профессионального союза работников государственных учреждений и общественного обслуживания Российской Федерации»;

абзац третий пункта 5 изложить в следующей редакции:

«определение победителей конкурса (далее – лауреаты конкурса), а также наиболее отличившихся участников конкурса (далее – призеры конкурса);»;

в абзаце втором пункта 15 слова «лауреат определяется» заменить словами «лауреат конкурса и призер конкурса определяются»;

пункт 16 изложить в следующей редакции:

«16. Конкурсная комиссия может рекомендовать руководителю государственного органа Республики Татарстан рассмотреть следующие вопросы:

о присвоении лауреату конкурса классного чина в соответствии с частью 15 статьи $11^2$ Закона Республики Татарстан от 16 января 2003 года № 3-ЗРТ «О государственной гражданской службе Республики Татарстан»;

о направлении лауреата конкурса, призера конкурса на обучение по программам повышения квалификации либо профессиональной переподготовки.»;

в) в составе Конкурсной комиссии по организации и проведению Республиканского конкурса «Лучший государственный гражданский служащий Республики Татарстан» наименование должности О.А. Калашниковой изложить в следующей редакции: «председатель Татарстанской республиканской организации Общероссийского профессионального союза работников государственных учреждений и общественного обслуживания Российской Федерации (по согласованию)».

2. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 19 ноября 2015 года № УП-1111 «Об Электронной доске почета государственных гражданских служащих Республики Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 18 марта 2019 года № УП-172, от 2 сентября 2022 года № УП-615 и Указом Раиса Республики Татарстан от 28 июля 2023 года № 519) следующие изменения:

а) пункт 4 изложить в следующей редакции:

«4. Департаменту государственной службы и кадров при Раисе Республики Татарстан обеспечить:

ведение Электронной доски почета государственных гражданских служащих Республики Татарстан;

организацию обучения лиц, занесенных на Электронную доску почета государственных гражданских служащих Республики Татарстан, по программам повышения квалификации либо профессиональной переподготовки.»;

б) предложение второе пункта 16 Положения об Электронной доске почета государственных гражданских служащих Республики Татарстан изложить в следующей редакции:

«Это решение является основанием для принятия руководителем государственного органа Республики Татарстан следующих решений:

о поощрении государственного служащего по месту прохождения им государственной гражданской службы Республики Татарстан в порядке, установленном соответствующим государственным органом Республики Татарстан;

о направлении государственного служащего на обучение по программам повышения квалификации либо профессиональной переподготовки.».

3. Кабинету Министров Республики Татарстан обеспечить в установленном порядке финансирование расходов, связанных с исполнением настоящего Указа, а также принять иные решения, необходимые для его реализации.

4. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Раис**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
14 февраля 2025 года
№ 127

**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының иң яхшы дәүләт граждан хезмәткәре» республика конкурсы турында» Указына һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең электрон мактау тактасы турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының иң яхшы дәүләт граждан хезмәткәре» республика конкурсы турында» 2014 елның 16 маендагы ПУ-479 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 27 июнендәге ПУ-604 номерлы, 2017 елның 21 августындагы ПУ-719 номерлы, 2021 елның 27 февралендәге ПУ-188 номерлы, 2022 елның 3 сентябрендәге ПУ-618 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 25 августындагы 590 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) «Татарстан Республикасының иң яхшы дәүләт граждан хезмәткәре» республика конкурсы турында нигезләмәдә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Конкурс кимендә ике елга бер тапкыр уздырыла.»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Конкурс йомгаклары буенча:

һәр конкурс төркемендә һәр номинациядә җиңүчеләр (алга таба – конкурс лауреатлары) билгеләнә, шул ук вакытта конкурс лауреатларының гомуми саны 12 дән артмаска тиеш;

һәр номинациядә өстәмә рәвештә конкурсның аеруча осталык күрсәткән катнашучылары (алга таба – конкурс призерлары) билгеләнә, шул ук вакытта конкурс призерларының гомуми саны 6 дан артмаска тиеш.»;

8 пунктта «ел саен 15 июльдән дә соңга калмыйча» сүзләрен төшереп калдырырга;

22 пунктта «конкурс лауреатларын бүләкләү турында» сүзләрен «конкурс лауреатларын бүләкләү һәм конкурс призерларын акчалата кызыксындыру турында» сүзләренә алмаштырырга;

23 пунктта «50 мең сум күләмендә» сүзләрен «100 мең сум күләмендә» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $23^{1}$ һәм $23^{2}$ пунктларын өстәргә:

«23[1]. Конкурс призерларына 50 мең сум күләмендә акчалата бүләк бирелә.

23[2]. Конкурс лауреатлары һәм конкурс призерлары Конкурс комиссиясе тәкъдиме белән квалификация күтәрү яисә яңадан һөнәри әзерлек бирү программалары буенча укырга җибәрелергә мөмкин.»;

б) «Татарстан Республикасының иң яхшы дәүләт граждан хезмәткәре» республика конкурсын оештыру һәм үткәрү буенча конкурс комиссиясе турында нигезләмәдә:

4 пунктта «Россия Федерациясенең дәүләт учреждениеләре һәм иҗтимагый хезмәт күрсәтү хезмәткәрләре һөнәр берлеге» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан республика оешмасы» сүзләрен «Россия Федерациясенең дәүләт учреждениеләре һәм иҗтимагый хезмәт күрсәтү хезмәткәрләре гомумроссия һөнәр берлеге Татарстан республика оешмасы» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«конкурста җиңүчеләрне (алга таба – конкурс лауреатлары), шулай ук конкурсның аеруча осталык күрсәткән катнашучыларын (алга таба – конкурс призерлары) билгеләү;»;

15 пунктның икенче абзацында «лауреатны» сүзен «конкурс лауреаты һәм конкурс призеры» сүзләренә алмаштырырга;

16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Конкурс комиссиясе Татарстан Республикасы дәүләт органы җитәкчеләренә түбәндәге мәсьәләләрне карап тикшерүне тәкъдим итә ала:

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 11[2] статьясындагы 15 өлеше нигезендә конкурс лауреатына класслы чин бирү турында;

конкурс лауреатын, конкурс призерын квалификация күтәрү яисә яңадан һөнәри әзерлек бирү программалары буенча укырга җибәрү турында.»;

в) «Татарстан Республикасының иң яхшы дәүләт граждан хезмәткәре» республика конкурсын оештыру һәм үткәрү буенча конкурс комиссиясе составында О.А. Калашникованың вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Россия Федерациясенең дәүләт учреждениеләре һәм иҗтимагый хезмәт күрсәтү хезмәткәрләре гомумроссия һөнәр берлеге Татарстан республика оешмасы рәисе (килешү буенча)».

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең электрон мактау тактасы турында» 2015 елның 19 ноябрендәге ПУ-1111 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2019 елның 18 мартындагы ПУ-172 номерлы, 2022 елның 2 сентябрендәге ПУ-615 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 28 июлендәге 519 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең электрон мактау тактасын алып баруны;

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең электрон мактау тактасына кертелгән затларны квалификация күтәрү яисә яңадан һөнәри әзерлек бирү программалары буенча укытуны оештыруны.»;

б) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең электрон мактау тактасы турында нигезләмәнең 16 пунктындагы икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бу карар Татарстан Республикасы дәүләт органы җитәкчесе тарафыннан түбәндәге карарлар кабул ителүгә нигез булып тора:

дәүләт хезмәткәрен ул Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте узган урында Татарстан Республикасының тиешле дәүләт органында билгеләнгән тәртиптә бүләкләү турында;

дәүләт хезмәткәрен квалификация күтәрү яисә яңадан һөнәри әзерлек бирү программалары буенча укырга җибәрү турында.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны үтәү белән бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә, шулай ук аны гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка карарлар кабул итәргә.

4. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2025 ел, 14 февраль
№ 127